а) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) округ комиссияләре төзелмәгән йә аларның вәкаләтләре билгеләнгән тәртиптә башка комиссияләргә йөкләнмәгән очракларда округ комиссияләре вәкаләтләрен башкара»;

б) 20 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

22) 108[1] статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Округ комиссияләре төзелмәскә дә мөмкин. Бу очракта округ комиссиясе вәкаләтләрен муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе карары белән муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе яисә участок комиссиясе башкарырга мөмкин.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе мөрәҗәгате нигезендә кабул ителгән карары буенча округ комиссиясе вәкаләтләре территориаль комиссиягә йөкләнергә мөмкин.»;

23) 117 статьяның 4 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

24) 132 статьяның 2[1] өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2[1]. Әлеге Кодексның 60 статьясындагы 13 өлеше нигезләмәләре «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 28 июнендәге 33-ТРЗ номер-

лы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергән көннән соң билгеләнгән сайлауларда депутатлары сайланган чакырылыштан соң килгән чакырылышларга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларны үткәрүгә бәйле барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.»;

25) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘЛӘРГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАСЫ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘЛӘРНЕҢ ӘЛЕГЕ КОДЕКСНЫҢ 78 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

| | |
|---|---|
| 1 күбрәк яисә тигез | 3 + 5 + 6 |
| 2 тигез | – 4 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13 |
| 8 + 9 тигез | 10 + 11 |
| 11 тигез | 14 + беркетмәнең калган барлык юллары»; |

26) 10 нчы кушымтада «вазыйфасын күрсәтеп, муниципаль берәмлек башлыгы», «яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5 ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның 6 пунктындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Инициатив төркемнең үтенечнамәсенә күрсәтелгән төркемнең барлык әгъзалары имза салырга тиеш, ә референдум үткәрү инициативасы белән сайлау берләшмәсе, башка иҗтимагый берләшмә чыккан очракта, үтенечнамәгә әлеге



сайлау берләшмәсенең, башка иҗтимагый берләшмәнең җитәкче органының йә аның референдум үткәрү инициативасы белән чыгу турындагы карарны хуплаган региональ бүлеге яисә башка структур бүлекчәсе җитәкче органының барлык әгъзалары имза салырга тиеш.»;

2) 43 статьяның 6 пунктында «Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп» сүзләрен «Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп» сүзләренә алмаштырырга;

3) 44 статьяда:
а) 5 пунктның «о» пунктчасына «, шулай ук чит ил агенты функциясен үтәүче коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләрен өстәргә;
б) 10 пунктта «Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп» сүзләрен «Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп» сүзләренә алмаштырырга, «аларны тоту турында» сүзләреннән соң «, шул исәптән һәр операция буенча,» сүзләрен өстәргә;
в) түбәндәге эчтәлекле 11 һәм 12 өлешләр өстәргә:
«11. Референдум фондының махсус счетына акчалар керү һәм әлеге акчаларның тотылуы турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына урнаштыра. Түбәндәге белешмәләрне урнаштыру мәҗбүри:
а) тиешле референдум фондыннан акчаларның тотылуы буенча финанс операциясе турында, әгәр аның күләме 50 мең сумнан артык булса;
б) тиешле референдум фондына 25 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары күчергән юридик затлар турында;
в) тиешле референдум фондына 20 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары керткән гражданнарның саны турында;
г) иганәчеләргә референдум фондыннан кире кайтарылган акчалар турында, шул исәптән кире кайтару нигезләре хакында;
д) тиешле референдум фондына кергән акчаларның гомуми суммасы турында һәм тотылган акчаларның гомуми суммасы турында.
12. Әлеге статьяның 11 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән күләмдә гамәлгә ашырыла.»;

4) 46 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«46 статья. **Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршындагы контроль-ревизия хезмәте**

1. Референдум әзерләү һәм уздыру өчен комиссияләргә бүлеп бирелгән акчаларның максатчан тотылуын, акчаларның референдум фондларына керү чыганакларын, әлеге акчаларны һәм алардан файдалануны исәпкә алуны оештыруны тикшереп тору, инициатив төркемнең финанс хисабын тикшерү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршында контроль-ревизия хезмәте төзелә.
2. Контроль-ревизия хезмәте дәүләт органнарыннан һәм башка органнардан, оешмалардан һәм учреждениеләрдән, моңа Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе һәм Россия Федерациясе Саклык банкы филиалы да керә, белгечләрне (шул исәптән җитәкчеләрне) җәлеп итеп төзелә. Күрсәтелгән органнар һәм учреждениеләр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе таләбе буенча, референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, белгечләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карамагына җибәрергә тиеш. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карамагына белгечләр кимендә биш айга җибәрелә.
3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән белгечләр контроль-ревизия хезмәтендә эшләү чорына төп эшләреннән азат ителә, аларның эш урыны (вазыйфасы), төп эш урыны буенча билгеләнгән вазыйфаи окладлары һәм башка түләүләр сакланып кала, аларга шулай ук референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән акчалата бүләкләүләр бирелергә мөмкин.
4. Контроль-ревизия хезмәте турында нигезләмә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Контроль-ревизия хезмәте эшчәнлеген оештыру, хокукый, матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.
5. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда контроль-ревизия хезмәте «Сайлаулар» ДАС тан файдаланырга мөмкин.»;

5) 47 статьяга түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:
«9. Тавыш бирү бинасын җиһазлаганда референдумда катнашучы инвалидлар әлеге бинага тоткарлыксыз кереп тавыш бирсен өчен Россия Федерациясе законнарында каралган шартлар тәэмин ителергә тиеш. Тавыш бирү үткәрелгәндә мондый затларның актив сайлау хокукын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының



һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда, башка федераль законнарда каралган таләпләрне үтәп, аларга булышлык күрсәтелә.»;

6) 49 статьяның 7 пунктында «Заказга» сүзен «Контрактка» сүзенә алмаштырырга;

7) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘЛӘРГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАСЫ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘЛӘРНЕҢ ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 52 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

| | |
|---|---|
| 1 күбрәк яисә тигез | 3 + 5 + 6 |
| 2 тигез | 3 – 4 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13 |
| 8 + 9 тигез | 10 + 11 |
| 11 тигез | 14 + беркетмәнең калган барлык юллары». |

**3 статья**

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяның 5 пунктындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Инициатив төркемнең үтенечнамәсенә күрсәтелгән төркемнең барлык әгъзалары имза салырга тиеш, ә референдум үткәрү инициативасы белән сайлау берләшмәсе, башка иҗтимагый берләшмә чыккан очракта үтенечнамәгә әлеге сайлау берләшмәсенең, башка иҗтимагый берләшмәнең җитәкче органының йә аның референдум үткәрү инициативасы белән чыгу турындагы карарны хуплаган региональ бүлеге яисә башка структур бүлекчәсе җитәкче органының барлык әгъзалары имза салырга тиеш.»;

2) 45 статьяның 6 пунктында «Татарстан Республикасы Милли банкы белән килешеп» сүзләрен «Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп» сүзләренә алмаштырырга;

3) 46 статьяда:

а) 5 пунктның «о» пунктчасына «, шулай ук чит ил агенты функциясен үтәүче коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләрен өстәргә;

б) 11 пунктта «Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп» сүзләрен «Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп» сүзләренә алмаштырырга, «тоту турында» сүзләреннән соң «, шул исәптән һәр операция буенча,» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 12 һәм 13 өлешләр өстәргә:

«12. Референдум фондының махсус счетына акчалар керү һәм әлеге акчаларның тотылуы турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына урнаштыра. Түбәндәге белешмәләрне урнаштыру мәҗбүри:

а) тиешле референдум фондыннан акчаларның тотылуы буенча финанс операциясе турында, әгәр аның күләме 50 мең сумнан артык булса;

б) тиешле референдум фондына 25 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары күчергән юридик затлар турында;

в) тиешле референдум фондына 20 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары керткән гражданнарның саны турында;

г) иганәчеләргә референдум фондыннан кире кайтарылган акчалар турында, шул исәптән кире кайтару нигезләре хакында;

д) тиешле референдум фондына кергән акчаларның гомуми суммасы турында һәм тотылган акчаларның гомуми суммасы турында.

13. Әлеге статьяның 12 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән күләмдә гамәлгә ашырыла.»;

4) 48 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«48 статья. **Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе контроль-ревизия хезмәте**

1. Референдум әзерләү һәм уздыру өчен комиссияләргә бүлеп бирелгән акчаларның максатчан тотылуын, акчаларның референдум фондларына керү чыганакларын, әлеге акчаларны



һәм алардан файдалануны исәпкә алуны оештыруны тикшереп тору, инициатив төркемнең финанс хисабын тикшерү өчен муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе каршында контроль-ревизия хезмәте төзелә.

2. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе каршындагы контроль-ревизия хезмәте дәүләт органнарыннан һәм башка органнардан, оешмалардан һәм учреждениеләрдән, моңа Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе һәм Россия Федерациясе Саклык банкы филиалы да керә, белгечләрне (шул исәптән җитәкчеләрне) җәлеп итеп төзелә. Күрсәтелгән органнар һәм учреждениеләр муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе таләбе буенча, референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, белгечләрне муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе карамагына җибәрергә тиеш. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе карамагына белгечләр кимендә ике айга җибәрелә.

3. Әлеге статьяның 2 пунктында күрсәтелгән белгечләр контроль-ревизия хезмәтендә эшләү чорына төп эшләреннән азат ителә, аларның эш урыны (вазыйфасы), төп эш урыны буенча билгеләнгән вазыйфаи окладлары һәм башка түләүләр сакланып кала, аларга шулай ук референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән акчалата бүләкләүләр бирелергә мөмкин.

4. Контроль-ревизия хезмәте турында нигезләмә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Контроль-ревизия хезмәте эшчәнлеген оештыру, хокукый, матди-техник тәэмин итү муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда контроль-ревизия хезмәте «Сайлаулар» ДАС тан файдаланырга мөмкин.»;

5) 49 статьяга түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9. Тавыш бирү бинасын җиһазлаганда референдумда катнашучы инвалидлар әлеге бинага тоткарлыксыз кереп тавыш бирсен өчен Россия Федерациясе законнарында каралган шартлар тәэмин ителергә тиеш. Тавыш бирү үткәрелгәндә мондый затларның актив сайлау хокукын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда, башка федераль законнарда каралган таләпләрне үтәп, аларга булышлык күрсәтелә.»;

6) 51 статьяның 7 пунктында «Заказга» сүзен «Контрактка» сүзенә алмаштырырга;

7) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘЛӘРГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАСЫ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘЛӘРНЕҢ ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 54 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

| | |
|---|---|
| 1 күбрәк яисә тигез | 3 + 5 + 6 |
| 2 тигез | 3 – 4 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13 |
| 8 + 9 тигез | 10 + 11 |
| 11 тигез | 14 + беркетмәнең калган барлык юллары». |

**4 статья**

«Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» 2012 елның 25 декабрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 39 статьяның 4 өлешендә «Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп» сүзләрен «Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп» сүзләренә алмаштырырга;

2) 40 статьяда:

а) 5 өлешнең 14 пунктына «, шулай ук чит ил агенты функциясен үтәүче коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләрен өстәргә;

б) 13 өлештә «Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп» сүзләрен «Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп» сүзләренә алмаштырырга, «акчаларны тотуны» сүзләреннән соң «, шул исәптән һәр операция буенча,» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 14 һәм 15 өлешләр өстәргә:



«14. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының махсус счетына акчалар керү һәм әлеге акчаларның тотылуы турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына урнаштыра. Түбәндәге белешмәләрне урнаштыру мәҗбүри:

1) тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фондыннан акчаларның тотылуы буенча финанс операциясе турында, әгәр аның күләме 50 мең сумнан артык булса;

2) тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына 25 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары күчергән юридик затлар турында;

3) тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына 20 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары керткән гражданнарның саны турында;

4) иганәчеләргә тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фондыннан кире кайтарылган акчалар турында, шул исәптән кире кайтару нигезләре хакында;

5) тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына кергән акчаларның гомуми суммасы турында һәм тотылган акчаларның гомуми суммасы турында.

15. Чакыртып алу буенча тавыш бирү үткәрелгәндә әлеге статьяның 14 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән күләмдә гамәлгә ашырыла.»;

3) 42 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«42 статья. **Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршындагы контроль-ревизия хезмәте**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләү һәм уздыру өчен комиссияләргә бүлеп бирелгән акчаларның максатчан тотылуын, акчаларның чакыртып алу буенча тавыш бирү фондларына керү чыганакларын, әлеге акчаларны һәм алардан файдалануны исәпкә алуны оештыруны тикшереп тору, инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемнең финанс хисабын тикшерү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршында контроль-ревизия хезмәте төзелә.

2. Контроль-ревизия хезмәте дәүләт органнарыннан һәм башка органнардан, оешмалардан һәм учреждениеләрдән, моңа Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе һәм Россия Федерациясе Саклык банкы филиалы да керә, белгечләрне (шул исәптән җитәкчеләрне) җәлеп итеп төзелә. Күрсәтелгән органнар һәм учреждениеләр Та-

тарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе таләбе буенча, чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, белгечләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карамагына кимендә биш айга җибәрергә тиеш.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән белгечләр контроль-ревизия хезмәтендә эшләү чорына төп эшләреннән азат ителә, аларның эш урыны (вазыйфасы), төп эш урыны буенча билгеләнгән вазыйфаи окладлары һәм башка түләүләр саклanып кала, аларга шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирү әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән акчалата бүләкләүләр бирелергә мөмкин.

4. Контроль-ревизия хезмәте турында нигезләмә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Контроль-ревизия хезмәте эшчәнлеген оештыру, хокукый, матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда контроль-ревизия хезмәте «Сайлаулар» ДАС тан файдаланырга мөмкин.»;

4) 43 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш өстәргә:

«10. Тавыш бирү бинасын җиһазлаганда чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы инвалидлар әлеге бинага тоткарлыксыз кереп тавыш бирсен өчен Россия Федерациясе законнарында каралган шартлар тәэмин ителергә тиеш. Тавыш бирү үткәрелгәндә мондый затларның актив сайлау хокукын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда, башка федераль законнарда каралган таләпләрне үтәп, аларга булышлык күрсәтелә.»;

5) 45 статьяның 7 өлешендә «Заказга» сүзен «Контрактка» сүзенә алмаштырырга;



6) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентын
чакыртып алу тәртибе турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘЛӘРГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАСЫ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘЛӘРНЕҢ ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 48 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

| | |
|---|---|
| 1 күбрәк яисә тигез | 3 + 5 + 6 |
| 2 тигез | 3 – 4 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13 |
| 8 + 9 тигез | 10 + 11 |
| 11 тигез | 14 + беркетмәнең калган барлык юллары»; |

**5 статья**

1. Әлеге Закон, шушы статья белән үз көченә керүнең башка срогы билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 17 пункты, 2 статьясындагы 5 пункты, 3 статьясындагы 5 пункты һәм 4 статьясындагы 4 пункты 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 8 мае
№ 34-ТРЗ

## 457. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2[1] статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8; 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле 3[1] өлеш өстәргә:

«3[1]. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Россия Федерациясе субъектларына хезмәт ресурсларын җәлеп итү өстенлекле булып торган Россия Федерациясе субъектлары исемлегенә (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлек) кертелмәгән Россия Федерациясе субъектларының хезмәт ресурсларын җәлеп итү өчен шартлар тудыруны күздә тота торган республика хезмәт ресурслары мобильлеген арттыру программасын (алга таба – республика программасы) әзерләргә, расларга һәм гамәлгә ашырырга хокуклы. Республика программасы Татарстан Республикасында инвестиция проектларын һәм күрсәтелгән программада катнашу турында эш бирүчеләр белән төзелгән килешүләрне гамәлгә ашыруны исәпкә алып әзерләнә. Республика программасында катнашу хакындагы килешүгә кертү өчен мәҗбүри шартлар, эш бирүчеләрнең күрсәтелгән программада катнашу тәртибе «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы белән билгеләнә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты түбәндәгеләрне билгели:



1) республика программасына кертелергә тиешле инвестиция проектларын сайлап алу тәртибен һәм критерийларын;

2) республика программасында катнашу турында эш бирүче белән төзелә торган килешүгә кертү шартларын, шул исәптән эшкә урнаштыру өчен җәлеп ителгән гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының яңа урында урнашуына бәйле шартларны;

3) эш бирүченең республика программасында катнашуын раслый торган һәм аңа финанс ярдәме алу хокукын бирә торган сертификат (алга таба – сертификат) алуга хокуклы эш бирүчеләрне сайлап алу тәртибен һәм критерийларын;

4) эш бирүчеләргә сертификатта каралган финанс ярдәмен күрсәтү тәртибен;

5) сертификатны кире кайтару тәртибен.»;

2) 4 өлешнең 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«эш бирүчеләргә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлеккә кертелмәгән Россия Федерациясе субъектларының хезмәт ресурсларын җәлеп итүдә ярдәм күрсәтү;»;

3) 5 өлештә «гамәлгә ашыру функцияләрен башкаручы органнары» сүзләрен «гамәлгә ашыру функцияләрен башкаручы органы» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 8 мае
№ 35-ТРЗ

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 458. «Татарстан Республикасы депутатларының һәм җәмәгатьчелегенең Татарстанның яңа тарихында парламентаризм үсешенең 25 еллыгына багышланган тантаналы җыелышы турыда» 2015 елның 13 мартындагы 461-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасы депутатларының һәм җәмәгатьчелегенең Татарстанның яңа тарихында парламентаризм үсешенең 25 еллыгына багышланган тантаналы җыелышы турыда» 2015 елның 13 мартындагы 461-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Татарстан Республикасы депутатларының һәм җәмәгатьчелегенең Татарстанның яңа тарихында парламентаризм үсешенең 25 еллыгына багышланган тантаналы җыелышын 2015 елның 30 маенда С.Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концертлар залында уздырырга (Казан шәһәре, Ирек мәйданы).».

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 мае
№ 588-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 459. Татарстан Республикасы депутатларының һәм җәмәгатьчелегенең Татарстанның яңа тарихында парламентаризм үсешенең 25 еллыгына багышланган тантаналы җыелышын телевидение һәм радио аша турыдан-туры трансляцияләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы депутатларының һәм җәмәгатьчелегенең Татарстанның яңа тарихында парламентаризм үсешенең 25 еллыгына багышланган тантаналы җыелышын 2015 елның 30 маенда телевидение һәм радио аша турыдан-туры трансляцияләүне оештырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 мае
№ 589-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 460. М.Ш. Шәймиевне Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Шәймиев Минтимер Шәрип улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 мае
№ 590-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 461. В.И. Матвиенконы Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы Рәисе Матвиенко Валентина Ивановнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәмметшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 мае
№ 591-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 462. Р.Н. Миңнехановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Миңнеханов Рөстәм Нургали улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәмметшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 мае
№ 592-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 463. И.Р. Таһировны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры Таһиров Индус Риза улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәмметшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 мае
№ 593-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 464. В.Н. Липужинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Липужина Валентина Николаевнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәмметшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 мае
№ 594-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 465. Р.И. Вәлиевне Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Вәлиев Разил Исмәгыйль улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 мае
№ 595-V ДС



# III
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘЛӘРЕ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 466. Л.Ф. Вәлиеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы Вәлиева Лена Фарук кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 5 мае
№ 336-РК

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 467. Б.Х. Зиннуровны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» ЮһБ ФДБМУ административ эш һәм филиаллар буенча проректоры Зиннуров Булат Хәнәфи улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 7 мае
№ 341-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 468. О.А. Егорованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «ИД «Комсомольская правда» ЯАҖ Казан филиалының интернет-версия буенча директор урынбасары Ольга Александровна Егорованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 8 мае
№ 342-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 469. Н.С. Ульяничеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Канал 6» ЯАҖ сату департаменты директоры Наталья Сергеевна Ульяничеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 8 мае
№ 343-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 470. Г.М. Шәриповаңы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Татмедиа» ачык акционер җәмгыяте филиалы «Хезмәт даны» газетасы редакциясе» директоры — баш редакторы Шәрипова Гөлгенә Мөдәрис кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 8 мае
№ 344-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 471. Ф.Ф. Мәүлетовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Татмедиа» ААҖ филиалы «Саба таңнары» газетасы редакциясе» баш мөхәррир урынбасары — җаваплы секретарь Мәүлетов Фәнил Фәһим улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 8 мае
№ 345-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 472. А.Н. Хәбипованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Татмедиа» ачык акционер җәмгыяте филиалы «Хезмәткә дан» газетасы редакциясе»нең хатлар бүлеге редакторы Хәбипова Айгөл Наил кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 8 мае
№ 346-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 473. М.Ш. Низаметдинованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Татмедиа» ачык акционер җәмгыяте филиалы «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы» яңалыкларның татар телендәге чыгарылышы редакциясе баш редакторы Низаметдинова Миләүшә Шамил кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 8 мае
№ 347-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 474. Р.Г. Мәрдановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Татмедиа» ачык акционер җәмгыяте филиалы «Шәһри Казан» газетасы редакциясе» корректоры Мәрданова Рәзинә Габдерәфыйкъ кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 8 мае
№ 348-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 475. И.С. Фәттаховны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Татмедиа» ААҖ филиалы «Арча хәбәрләре» газетасы редакциясе» бүлек мөхәррире Фәттахов Ильяс Сәхап улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 8 мае
№ 349-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 476. Е.В. Ширяеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Татмедиа» ачык акционер җәмгыяте филиалы «Челнинские известия» газетасы редакциясе» дизайнеры Елена Владимировна Ширяеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 8 мае
№ 350-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 477. «Бөгелмә авазы» газетасы редакциясе коллективын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Татмедиа» АҖ филиалы «Бөгелмә авазы» газетасы редакциясе» коллективын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 8 мае
№ 352-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 478. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 105-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (башкарма хакимиятнең республика органнарының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы белән үзара эшчәнлеге турындагы нигезләмәләр өстәлү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 105-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын 2015 елның 7 июленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 13 мае
№ 358-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 479. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Т. Борһанов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның эконом классны торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 106-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (терминнарны федераль законнарга тәңгәлләштерү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

